**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ —
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Россия Федерациясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) дәүләт системасының Татарстан Республикасында функцияләвен тәэмин итү чаралары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) өчен халык исәбен алу органнары тарафыннан Россия Федерациясе гражданнары турында мәгълүматлар бирү тәртибен камилләштерү максатларында, «Россия Федерациясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) дәүләт системасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең 2017 елның 19 апрелендәге 80/696-7 номерлы карары чыгарылу белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Россия Федерациясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) дәүләт системасының Татарстан Республикасында функцияләвен тәэмин итү чаралары турында» 2006 елның 1 мартындагы ПУ-78 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 29 августындагы ПУ-472 номерлы, 2008 елның 8 февралендәге ПУ-55 номерлы, 2010 елның 27 августындагы ПУ-574 номерлы, 2013 елның 9 сентябрендәге ПУ-868 номерлы, 2014 елның 10 апрелендәге ПУ-350 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктның беренче абзацында «Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәүне исәпкә алу органнары» сүзләрен «миграция өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашырырга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктның өченче абзацында «25 гыйнварыннан һәм 25 июленнән» сүзләрен «20 гыйнварыннан һәм 20 июленнән» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктта «Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең һәм Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары җитәкчеләренә» сүзләрен «Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

г) 1 нче кушымтада «Федераль миграция хезмәтенең территориаль органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре буенча идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

д) Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, башка дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләренең сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәгәндә (исәпкә алганда) һәм теркәлгән сайлаучыларның, референдумда катнашучыларның санын билгеләгәндә эшчәнлеген координацияләү буенча эш төркеме (алга таба – эш төркеме) составында:

эш төркеме составыннан Ф.Р. Волкованы, Э.А. Зарипованы, П.Н. Лохановны, И.Ш.Халиковны, Д.З.Хәмәдишинны, С.В.Чепуштановны чыгарырга;

эш төркеме составына кертергә:

Гәрәев Раил Рүзәл улын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбасарын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген координацияләү идарәсе башлыгын;

Глухова Лариса Юрьевнаны – Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгын;

Песошин Алексей Валерьевичны – Татарстан Республикасы Премьер-министрын, аны эш төркеме җитәкчесе итеп расларга;

Хиалиев Эдуард Данил улын – Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы вазыйфалары вәкаләтләрен вакытлыча башкаручыны (килешү буенча);

Шәвәлиева Альбина Рафаил кызын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгын.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 10 июль
№ ПУ-611